ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НӨНӘГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
7 апрель 2025 ел

КАРАР
№7

Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару һәм хуҗасыз хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 59 номерлы карары белән кабул ителгән «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Билгеләргә:

1) Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар (1 нче кушымта);

2) Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Хуҗасыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар формасын расларга (3 нче кушымта).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

Нөнәгәр авыл җирлеге
башлыгы: И.Н.Закиров

Кушымта

07.04.2025 ел № 7 Нөнәгәр авыл җирлеге башкарма комитеты карарына

Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар

1) парклар, скверлар территорияләре;
2) балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары;
3) спортның актив төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
4) зиратлар һәм мемориаль зоналар;
5) массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
6) балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
7) мәдәният объектларына якын территорияләр;
8) җәмәгать туклануы оешмаларына якын территорияләр;
9) сәүдә-күңел ачу үзәкләре территорияләре;
10) ваклап сату базарлары территорияләре;
11) йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар;
12) тимер юл һәм автомобиль вокзаллары (станцияләр), диңгез һәм елга портлары, аэропортлар (аэродромнар) территорияләрен;
13) калдыкларны урнаштыру объектларына якын территорияләр;
14) калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) чикләрендә территорияләр;
15) җылылык челтәрләре чикләрендә территорияләр;;
16) һәйкәлләр урнашкан территорияләр;
17) автобус тукталышлары яны.

Кушымта 2

07.04.2025ел № 7 Нөнәгәр авыл җирлеге башкарма комитеты карарына

Нөнәгәр авыл җирлегендә хуҗасыз хайваннарны, аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге

1) Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы

Кушымта 3

07.04.2025ел № 7 Нөнәгәр авыл
җирлеге башкарма комитеты
карарына

Форма

КАРАР
хуҗасыз хайваннарны, аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында

от «____» __________ 20__г. № ______

______________________________________________

(Ф.И.О., хуҗасыз хайваннарны кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазыйфасы)

тәкъдим ителгән нигезендә ______________________________________________
______________________ (аулау буенча махсуслаштырылган оешманың тулы исеме)
ветеринария өлкәсендә белгеч катнашында агрессивлыгы булу (булмау)га уздырылган хуҗасыз хайванны тикшерү ___ номерлы "_____"_____________ 20______ елның акты

хуҗасыз хайванга карата:
идентификация тамгасы ______________________________________________
аулау урыны һәм датасы
______________________________________________,
Кабул ителгән карар:
______________________________________________

(Хуҗасыз хайванны элеккеге яшәү урынына кайтару/кире кайтаруны тыю турында)

______________________________________________

(кабул ителгән карарның нигезе күрсәтелә)

______________________________________________

(имза) (Ф.И.О.)